**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТАБАР-ЧЕРКЕНЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Табар Черкене авыл җирлеге” муниципаль берәмлекнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

2018 ел, 12 октябрь №85

Шәһәр төзелеше кодексы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәләр оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге Советы **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге Советы 2014 ел, 7 август 71 нче номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Табар Черкене авыл җирлеге” муниципаль берәмлекнең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 25 статьяның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. Түбәндәге очракта төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителми:

1) физик затка эшмәкәрлек эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда бирелгән җир кишәрлегендә гараж төзү, реконструкцияләү яки торак йортның бакча җир участогында, бакча йортында, хуҗалык корылмаларын төзү, реконструкцияләү;

2) шәхси торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү;

3) капиталь төзелеш булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү;

4) җир участогында төзелеш эшләре һәм ярдәмче куллану корылмалар төзелеше;

5) капиталь төзелеш объектларының һәм алар өлешләренең ышанычлылыгы һәм иминлегенең конструктив һәм башка характеристикаларына кагылмаган үзгәрешләре, рөхсәт ителгән шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән төзелешнең, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан артмый;

6) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау;

7) җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән, килешенгән һәм расланган файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проекты белән яки җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга

бәйле эшләрне башкаруга башка проект документлары белән каралган бораулау скважиналарын төзү, реконструкцияләү;

8) 0,6 мегапаскальгә кадәр басым астында табигый газны транспортлау өчен билгеләнгән объектларны төзү, реконструкцияләү;

9) Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә төзелешкә рөхсәт алу таләп ителми торган башка очракларда";

б) 27 статьяның 8 пунктында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- төзелешкә рөхсәт бирү турында Карар кабул итү өчен кирәкле документларның булу-булмавын тикшерә";

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"-проект документларының линияле объект төзелешенә рөхсәт алу өчен бирелгән җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын төзүгә рөхсәт алу датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга карата билгеләнгән таләпләргә яки линияле объект төзелешенә территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә (линияле объектны төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), линияле объект төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә, шулай ук Россия Федерациясенең Җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән рөхсәт ителгән җир кишәрлеген һәм чикләүләрне куллану нигезендә капиталь төзелеш объектын урнаштыруны тикшерә. Рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт бирелгән очракта, затка рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрларыннан кире кагуга рөхсәт ителгән таләпләргә туры килү буенча проект документларын тикшерү үткәрелә";

в) 28 статьяда:

9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"9. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге түбәндәге очракларда гамәлгә ашырыла:

1) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә проект документлары экспертизага тиешле капиталь төзелеш объектлары төзелешенә;

2) капиталь төзелеш объектларын үзгәртеп коруга, шул исәптән, капиталь төзелеш объектларын, шул исәптән мәдәни мирас объектларын саклау буенча капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә проект документлары, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә экспертиза үткәрелергә тиеш булса, мондый объектларның ышанычлылыгы һәм иминлегенең башка характеристикаларына кагылышлы мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкарганда да экспертиза үткәрелергә тиеш";

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"10. Капиталь төзелеш объектларына карата дәүләт төзелеш күзәтчелеге

әлеге статьяның 9 өлешендә күрсәтелгән объектларга карата куллана. Дәүләт төзелешен күзәтү предметы булып, капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору процессында эшләр башкаруның һәм кулланыла торган төзелеш материалларының, шулай ук мондый эшләрнең нәтиҗәләренең проект документлары таләпләренә, шул исәптән энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә туры килүен тикшерү тора (энергетика нәтиҗәлелеге таләпләре таралмый торган капиталь төзелеш объектларыннан тыш) һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителеше таләпләренә туры килә; Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 2, 3 һәм 3.1 өлешләрендә билгеләнгән таләпләрне үтәү”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге Уставы нигезендә махсус мәгълүмати стендларда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Табар Черкене авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Табар Черкене авыл**
**җирлеге башлыгы** **Р.Х.Ибатуллин**